**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү мәсьәләләре буенча даими эш төркеме составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү тәртибе турында» 2008 елның 5 сентябрендәге ПУ-445 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-211 номерлы, 2010 елның 18 августындагы ПУ-536 номерлы, 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы, 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2013 елның 6 мартындагы ПУ-199 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-305 номерлы, 2015 елның 7 октябрендәге ПУ-973 номерлы, 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2017 елның 14 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы һәм 2018 елның 27 ноябрендәге ПУ-805 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү мәсьәләләре буенча даими эш төркеме составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) эш төркеме составыннан Ф.С. Габделганиевны, Р.Р. Гыйматдиновны, А.Б. Гревцовны, А.К. Хамаевны чыгарырга;

б) эш төркеме составына кертергә:

Әгълиуллин Фәнил Әнвәр улын – Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрын;

Бакиров Газинур Тәлгать улын – Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесен;

Долгов Марат Шамил улын – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгын;

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улын – Татарстан Республикасы икътисад министрын.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 22 июнь
№ ПУ-359

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ